КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 июль г.Казань № 591

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларын норматив буенча финанслау турында» 2017 ел, 8 август, 566 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларын норматив буенча финанслау турында» 2017 ел, 8 август, 566 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 27 июль, 605 нче, 2018 ел, 13 ноябрь, 996 нчы; 2018 ел, 3 декабрь, 1077 нче; 2019 ел, 28 декабрь, 1232 нче, 2020 ел, 03 сентябрь, 785 нче, 2022 ел, 05 февраль, 92 нче, 2022 ел, 19 апрель, 370 нче; 2023 ел, 7 сентябрь, 1092 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Гомуми белем бирү оешмаларының мөлкәтен карап тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнарны исәпләп чыгару буенча җирле үзидарә органнары өчен методик тәкъдимнамәләрдә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары, шулай ук өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру чыгымнарына түбәндәгеләр керә:

коммуналь хезмәтләр (су белән тәэмин итү, су чыгару, җылылык белән тәэмин итү, электр белән тәэмин итү, каты коммуналь калдыкларны чыгару һәм утильләштерү) өчен түләүгә чыгымнар;

хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт хакына чыгымнар;

гомуми белем бирү оешмасы бассейнын карап тотуга чыгымнар;

гомуми белем бирү оешмасының элемтә хезмәтләренә чыгымнар;

гомуми белем бирү оешмасын дератизацияләү хезмәтләренә чыгымнар;

гомуми белем бирү оешмасының җылылык челтәрләрен опрессовкалауга чыгымнар.

Гомуми белем бирү оешмаларында озайтылган көн төркемнәрен оештыру чыгымнарына коммуналь хезмәтләр (су белән тәэмин итү, су чыгару, электр белән тәэмин итү, каты коммуналь калдыкларны чыгару һәм утильләштерү) өчен түләү чыгымнары гына керә.»;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Гомуми белем бирү оешмасы мөлкәтен карап тотуга (эксплуатацияләүгә) база нормативы түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:($BNSI^{t}_{vn}$)

$$BNSI^{t}_{vn} = \frac{K^{t}_{vf} + FOT^{t}_{v} + B_{i} + D^{t}_{i} + Cn_{vi} + O_{tsi}}{Sq^{t}_{v}},$$

монда:

$K^{t}_{vf}$ – коммуналь хезмәтләргә чыгымнар күләме;

$FOT^{t}_{v}$ – хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт хакына чыгымнар күләме;

$B_{i}$ – гомуми белем бирү оешмасының бассейнын карап тотуга чыгымнар күләме;

$D^{t}_{i}$ – дератизация хезмәтләре өчен чыгымнар күләме;

$Cn_{vi}$ – гомуми белем бирү оешмасында элемтә хезмәтләренә чыгымнар күләме;

$O_{tsi}$ – әлеге Методик тәкъдимнамәләрнең 2.13 пункты нигезендә кабул ителә торган гомуми белем бирү оешмасының җылылык челтәрләрен опрессовкалауга чыгымнар күләме;

$Sq^{t}_{v}$ – 1 нче таблица нигезендә билгеләнә торган бер тәрбияләнүченең мәйданы белән тәэмин ителеш нормативы;

t – гомуми белем бирү оешмасының территориаль дислокациясе.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.13 пункт өстәргә:

«2.13. Гомуми белем бирү оешмасының җылылык челтәрләрен опрессовкалауга чыгымнар күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:($O_{tsi}$)

$$O_{tsi} = C_{tsi} \times Sq_{io} \times 12,$$

монда:

$C_{tsi}$ – гомуми белем бирү оешмасында җылыту челтәрләрен опрессовкалау өчен 1 айга җылытыла торган урын (бина) мәйданының 1 кв.метрына 1,15 сум исәбеннән билгеләнә торган норматив бәя;

$Sq_{io}$ – җылытыла торган бүлмә (бина) мәйданы;

12 – бер елда айлар саны.»;

3.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гомуми белем бирү оешмасының җылылык челтәрләрен опрессовкалауга чыгымнар.»;

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Гомуми белем бирү оешмасы мөлкәтен карап тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла: $(NSI_{ivf}^{t})$

$$NSI_{ivf}^{t} = \frac{K_{ivf}^{t} + FOT_{y_{vmob}}^{t} + B_i + Cn_{vi} + D_i^t + N_i + O_{tsi}}{Sq_i},$$

монда:

$K_{ivf}^{t}$ – гомуми белем бирү оешмасының коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрнең законнар нигезендә билгеләнгән тарифлары буенча коммуналь хезмәтләргә чыгымнарның төгәлләштерелгән күләме;

$FOT_{y_{vmob}}^{t}$ – хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт хакы өчен әлеге Методик тәкъдимнамәләрнең 2.6 пункты нигезендә кабул ителә торган чыгымнар күләме;

$B_i$ – гомуми белем бирү оешмасы бассейнын карап тоту өчен әлеге Методик тәкъдимнамәләрнең 2.7 пункты нигезендә кабул ителә торган чыгымнар күләме;

$Cn_{vi}$ – гомуми белем бирү оешмасында элемтә хезмәтләре өчен әлеге Методик тәкъдимнамәләрнең 2.9 пункты нигезендә кабул ителә торган чыгымнар күләме;

$D_i^t$ – дератизация хезмәтләре өчен әлеге Методик тәкъдимнамәләрнең 2.11 пункты нигезендә кабул ителә торган чыгымнар күләме;

$N_i$ – мөлкәтне агымдагы карап тотуга (эксплуатацияләүгә) башка чыгымнар;

$O_{tsi}$ – гомуми белем бирү оешмасының җылылык челтәрләрен опрессовкалау өчен әлеге Методик тәкъдимнамәләрнең 2.13 пункты нигезендә кабул ителә торган чыгымнар күләме;

$Sq_i$ – гомуми белем бирү оешмасының мәйдан белән факттагы тәэмин ителеше (бер белем алучыга).

Мөлкәтне агымдагы карап тотуга (эксплуатацияләүгә) башка чыгымнар түбәндәге формула буенча $(N_i)$исәпләп чыгарыла:

$$N_i = (K_{ivf}^{t} + FOT_{y_{vmob}}^{t}) \times 0{,}04,$$

монда:

$K_{ivf}^{t}$ – гомуми белем бирү оешмасының коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрнең законнар нигезендә билгеләнгән тарифлары буенча коммуналь хезмәтләргә чыгымнарның төгәлләштерелгән күләме;

$FOT_{y_{vmob}}^{t}$ – хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт хакына чыгымнар күләме;

0,04 – коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча норматив чыгымнар күләменнән һәм хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт өчен түләү фондыннан өлеш.»;

әлеге карар белән расланган Җирле үзидарә органнары өчен гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларның мөлкәтен карап тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнарны исәпләп чыгару буенча методик тәкъдимнамәләрдә:

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатның җылылык челтәрләрен опрессовкалауга чыгымнар.»;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатның мөлкәтен карап тотуга (эксплуатацияләүгә) база нормативы түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:($BNSI^t_v$)

$$BNSI^t_v = \frac{K^t_{vf} + D^t_{vi} + FOT^t_{y_{vmob}} + O_{tsii}}{Sq^t_v},$$

монда:

$K^t_{vf}$ – коммуналь хезмәтләргә чыгымнар күләме;

$D^t_{vi}$ – дератизация хезмәтләре өчен чыгымнар күләме;

$FOT^t_{y_{vmob}}$ – хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт хакына чыгымнар күләме;

$O_{tsii}$ – гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатның җылылык челтәрләрен опрессовкалау өчен әлеге Методик тәкъдимнамәләрнең 2.8 пункты нигезендә кабул ителә торган чыгымнар күләме;

$Sq^t_v$ – 1 нче таблица нигезендә бер тәрбияләнүчегә мәйдан белән тәэмин ителеш нормативы;

t – гомуми белем бирү оешмасының территориаль дислокациясе;

v – гомуми белем бирү оешмасының төре.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.8 пункт өстәргә:

«2.8. Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатның җылылык челтәрләрен опрессовкалауга чыгымнар күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:($O_{tsii}$)

$$O_{tsii} = C_{tsi} \times Sq_{iio} \times 12,$$

монда:

$C_{tsi}$ – гомуми белем бирү оешмасында җылыту челтәрләрен опрессовкалау өчен 1 айга җылытыла торган урын (бина) мәйданының 1 кв.метрына 1,15 сум исәбеннән билгеләнә торган норматив бәя;

$Sq_{iio}$ – гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатның җылытыла торган урын (бина) мәйданы;

12 – бер елда айлар саны.»;

3.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатның җылылык челтәрләрен опрессовкалауга чыгымнар.»;

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатның мөлкәтен карап тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла: ($NSI^t_{iv}$)

$$NSI_{iv}^{t} = \frac{K_{iv}^{t} + FOT_{y_{vmob}}^{t} + D_{vi}^{t} + N_i + O_{tsii}}{Sq_{ii}},$$

монда:

$K_{iv}^{t}$ – гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатның коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итүчеләренең законнар нигезендә билгеләнгән тарифлары буенча коммуналь хезмәтләргә чыгымнарның төгәлләштерелгән күләме;

$FOT_{y_{vmob}}^{t}$ – хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт хакы өчен әлеге Методик тәкъдимнамәләрнең 2.13 пункты нигезендә кабул ителә торган чыгымнар күләме;

$D_{vi}^{t}$ – дератизация хезмәтләре өчен әлеге Методик тәкъдимнамәләрнең 2.12 пункты нигезендә кабул ителә торган чыгымнар күләме;

$N_i$ – мөлкәтне агымдагы карап тотуга (эксплуатацияләүгә) башка чыгымнар;

$O_{tsii}$ – гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатның җылылык челтәрләрен опрессовкалау өчен әлеге Методик тәкъдимнамәләрнең 2.8 пункты нигезендә кабул ителә торган чыгымнар күләме;

$Sq_{ii}$ – гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатның мәйдан белән факттагы тәэмин ителеше (бер тәрбияләнүчегә).

Мөлкәтне агымдагы карап тоту (эксплуатацияләү) буенча башка чыгымнар түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:$N_i$)

$$N_i = (K_{ivf}^{t} + FOT_{y_{vmob}}^{t}) \times 0{,}04,$$

монда:

$K_{ivf}^{t}$ – гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатның коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итүчеләренең законнар нигезендә билгеләнгән тарифлары буенча коммуналь хезмәтләргә чыгымнарның төгәлләштерелгән күләме;

$FOT_{y_{vmob}}^{t}$ – хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт хакы өчен әлеге Методик тәкъдимнамәләрнең 2.13 пункты нигезендә кабул ителә торган чыгымнар күләме;

0,04 – коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча норматив чыгымнар күләменнән һәм хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт өчен түләү фондыннан өлеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин